ҖОМГА
26 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 20 (5820)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Профсоюз оешмаларының сугышчан бурычы

Профсоюз оешмаларына булган сайлаулардан соң ярты елдан артык вакыт үтте. Миллионнарча профсоюз членнарының актив катнашлары белән үткән бу сайлаулар профсоюз оешмаларының эшенә зур җанлылык керттеләр. Профсоюз оешмаларына яңа кадрлар тупланды. Предприятиеләрдәге һәм учреждениеләрдәге алдынгы стахановчылар—активистлар фабзавкомнарга, месткомнарга, цех комитетларына җитәкчелек итә башладылар. Профсоюз җәмагатчелеге аларга зур ышаныч белдерде.

Заводларда, фабрикаларда һәм учреждениеләрдә соңгы елларда үскән, көрәштә чыныккан, киң катлау масса белән аралашкан яңа кешеләр профсоюз оешмаларына сайлангач, профсоюз эше яңа баскычка күтәрелде, алар профсоюз аппаратын массага якынайттылар, тәрбия эшләрен киң күләмдә җәеп җибәрделәр, алар массаның активлыгына җитәкчелекне сизелерлек рәвештә яхшырттылар. Октябрь алды ярышының, җирле Советларга сайлауларга хәзерлек кампаниясенең һәм сайлауларның искиткеч зур уңышлар белән үтүе моңа бик ачык үрнәк булып торалар.

Профсоюз оешмаларына җитәкчелек эшенә килгән бу яңа кадрлар миллионнарча профсоюз членнарын үзләре артыннан ияртеп баралар, производствога яңалыклар кертүгә үзләре инициаторлар булып торалар, стахановча эшләүнең соклангыч үрнәкләрен күрсәтәләр. Моңа безнең республикабыздан гына да бик күп мисаллар китерергә мөмкин. Мәсәлән, „Спартак“ комбинатының парусин цехындагы профорг, Казан шәһәр советының депутаты Селикова, утиль цехының цехком председателе Бабайкова, цехком председателе урынбасары Әюпова, штамповочный цехындагы цехком председателе Меркулов иптәшләр комбинатның мактаулы стахановчылары, социалистик ярышны оештыруның энтузиастлары, алдан баручылары булып саналалар. Алар күпләр өчен үрнәк булып торалар, күпләр алардан үрнәк алалар, өйрәнәләр, алар кебек булырга тырышалар. Иптәш Меркулов штамповочный цехта һәм тулаем комбинатта „Менче“ дигәндан алган. Аның хезмәт хакы ай саен мең сумнан артык була!

Яки менә Радвугин һәм Кораблкова иптәшләр. Болар Дәүләт Банкысының республика конторасының местком членнары, банк коллективының отличниклары. Алар һәр вакыт алдынгылык күрсәтәләр. Бездә мондый алдынгыларны күпләп санарга мөмкин.

Профсоюз оешмаларының эшендә беренче уңышлар күз алдында. Ләкин бу әле аларның эшләрендә кимчелекләр бөтенләй юк дигән сүз түгел. Профсоюз оешмаларының практик эшләрен партиянең XVIII нче съезды тарафыннан, иптәш Сталин тарафыннан куелган бөек бурычлар югарылыгына күтәрү буенча, әле профсоюз членнары арасында массовый-тәрбия эшләрен тагын да яхшыртуда, профсоюзларның эчке демократиясен тулысынча тормышка ашыруда тагын да яхшырак эшлисе бар. Ә эчке демократияне тормышка ашыруда кайбер оешмаларда тупас бозулар да юк түгел. Мәсәлән, тегүчеләр союзының шәһәр комитеты, „Спартак“ фабкомы, дәүләт банк месткомы, пишмаш завкомы сайлаулардан соң алты ай вакыт үтүгә карамастан, сайлаучылар алдында отчет биргәннәре юк. Ә устав буенча отчет һәр квартал саен булырга тиеш.

Москвадагы инструменталь заводы коллективының мөраҗәгате профсоюз оешмаларына яңа бурычлар йөкли. Стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итү, күп станокларда эшләүчеләр һәм күп профессияләрне бер үк вакытта башкаручылар сафын тулыландыру өчен көрәш профсоюз оешмалары эшенең беренче планында торырга тиеш. Бу гүзәл хәрәкәткә җанлы җитәкчелекне тәэмин итәргә кирәк. Производство киңәшмәләренең эше кайнап торырга тиеш. Күп станокларда эшләүчеләр һәм күп профессияне үтәүчеләрнең тәҗрибәләрен уртаклашу, уйлап табучылар һәм рационаллаштыручылар фикрен туплау, аны тагын да үстерү производство киңәшмәләре көн тәртибенең төп мәсьәләре булырга тиешләр.

Профгруппорглар — профсоюзның массага иң якын вәкилләре. Алардан бик күп нәрсә таләп ителә. Алар алдынгы стахановчы булырга, социалистик ярышның инициаторы булырга, хезмәт дисциплинасы өчен көрәшергә, эшкә комачаулаучыларга каршы җәмагат фикрен тупларга тиешләр. Алар производствоның чикләнмәгән мөмкинлекләрен, резервларын табуда да зур булышлык күрсәтә алалар. Профгруппорглар белән тик эшләргә генә кирәк.

Массаның активлыгын туплау өчен, эштәге кимчелекләрне тизлек белән бетерү өчен һәм массаның көндәлек эшеннән аерылмау өчен фабзавкомнарның һәм месткомнарның отчетларын һәр квартал саен тәртипле рәвештә үткәрергә кирәк. Профсоюз демократиясен бозу фактларына юл куелмасын! Сайлаучыларның наказларын үтәмәү яки үтәп тә ул турыда отчет бирмәү өчен һичбер нәрсә сәбәп була алмый, аны бер нәрсә белән дә аклап булмый. Профсоюз устафы, ВЦСПС карарлары һичбер сүзсез үтәлергә тиешләр.

Сталинчыл өченче бишьеллыкның **хезмәт җитештерүчәнлеге планын дүрт елда үтәү** өчен башланган хәрәкәт миллионнарның иҗад көчен туплый, производствода яңа активлыкны күтәрә. Хезмәт ияләре үз иленең байлыгын арттыру, оборона куәтен ныгыту эшенә бөтен көчләрен куялар. Бу гүзәл хәрәкәткә җитәкчелек итү, аны тагын да киңәйтү— профсоюз оешмаларының сугышчан бурычлары!

РӘСЕМДӘ: (уннан сулга) С. К. Бадигин—СССР Наркомземы аграномы („Седов“ бозватк ычы капитанының атасы), К. С. Бадигинның бала вакыттагы дусты В. В. Полядько—Москва шәһәре станкоинструментальный институтның аспиранты, кыз туганы Е. Б. Иванова, кыз туганы Евгения—СССР ның ленин орденлы Зур Драма театрының хореаграфик техникум студенткасы һәм анасы Е. И. Бадигина—Сталин исемендәге автозавод поликлиникасы врачы „Седов“ бозваткычының дрейфе турындагы хәбәрне укыйлар.

В. Зунин фотосы (ТАСС фото—клишесе).

КАДЕРЛЕ, СӨЕКЛЕ ВАТАН ЯРЛАРЫНА ТАБА

„И. Сталин“ бозваткычы борты, 24 гыйнвар. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән радио буенча). Ачык диңгездә бункеровка бик катлаулы эш булып чыкты. „И. Сталин“ һәм „Г. Седов“ бозваткычлары боз кырыенда „Сталинград“ пароходы белән очрашкач та, күмерне трюмнарга күчерү эше башланды, ләкин бу эш озакка бармады. 3 караб бер-берсе белән рәттән—бортка-борт килгән хәлдә тордылар. „Сталинград“ уртада, „И. Сталин“ белән „Г. Седов“ як-якта. Куәтле краннар диңгездә килгән күмер базасын бушаттылар. Зур тырышлык белән алып барылган эш берничә сәгаткә сузылды. Шул вакытны, башта көчсез генә булган җил көчәйде. Зур дулкыннар күтәрелде. Дулкыннар өстендә, башка барлык бозваткычлар шикелле үк, флагман да чайкалды һәм үзенең көчле корпусы белән „Сталинград“ бортына бәрелергә кереште. Пароход селкенгәләде.

Бу чайкалуның дәвам итүе аркасында „Сталинград“ ның корпусында бозык урыннар барлыкка килүе һәм аның тагын да җиддиерәк зарарлануы мөмкин иде. Папанин „Сталинград“ белән бозлар арасына керергә һәм анда, тынычрак булган шартларда, бункеровканы дәвам иттерергә карар бирде. „Седов“ ул вакытта инде бераз күмер алып, кырыйга килеп җиткән иде. Флагман, „Сталинградка“ юл салып, бозлар арасына керде һәм, боз араларындагы ачыклыклардан файдаланып, диңгез дулкыннары сизелмәгән урынга килеп җитте.

Аврал иглан ителде. Экспедициянең барлык катнашучылары бункеровкага керештеләр. Берничә ун тонна күмер бушатып төяргә өлгерү белән, Бадигиннан хәбәр килде. „Седов“ны дулкыннар ачык диңгезгә алып чыкканнар. Көтелмәгән һәр төрле катлаулы хәлләрне булдырмас өчен, Папанин шунда ук бункеровканы туктатырга һәм „Седов“ ка таба барырга приказ бирде. Ләкин, Арктикада боз шартлары нинди үзгәрүчән! Көньякка таба юл тоташ бозлар белән капланган булып чыкты. Моннан берничә сәгат элек ачыклыклар булган урында, хәзер—ачык урыннары һич тә булмаган авыр, чиксез бозлар. Хәтта флагман да шушы ун баллы боз массивында үзенә юлны зур кыенлык белән генә ачты. „Сталинград“ минут саен артка калып барды. Пароход әйләнәсендәге бозларны вату өчен, бозваткычка кире кайтырга һәм тагын яңадан алга барырга туры килде. 4—5 миль чамасындагы ара 20 сәгаткә якын вакытны алды.

Папанин, капитан белән киңәшеп, бөтен эскадра белән Баренцбургка юнәлергә һәм анда, тыныч шартларда, карабларның бөтенлеген куркыныч астына куймыйча, күмер запасы алырга карар бирде. Кыска вакытка гына булган тукталудан файдаланып, иптәш Буйницкий урынны билгеләргә өлгерде: без 78 нче параллельдән бераз төньяктарак идек. Ләкин безнең урынның нинди озынлыкта икәнлеге иң кызыклы булып чыкты. Без җирнең икенче ярым шарында, Гринвич меридианының теге ягында идек.

Совет арктик караблары эскадрасы көньякка юнәлде. „Седов“ буксирга тагылган хәлдә флагман артыннан барды. Диңгез гаҗәп дәрәҗәдә тыныч булды. Сирәк-сирәк кенә яңа, юка бозлар очрый, алар карабларны үрмәкүч оясы шикелле генә тоткарлый алалар. „И. Сталин“ бозваткычы тулы ход белән барды, „Седов“ аны тоткарламады диярлек. Данлыклы „Седов“ның машинасы, ике ел эшләми торганнан соң, гаят яхшы эшләде. Гомумән, ачык диңгездә бару, бозлар арасындагы хәрәкәтнең иң авыр шартларына карамастан, седовчыларның карабтагы механизмнарны һәм җиһазларны иң яхшы саклаганлыкларын күрсәтте. Рейс вактында карабның руль хуҗалыгы да тикшерелде. Тикшерү яхшы нәтиҗәләр бирде. Ватык рульгә ремонт ясау буенча „Седов“ экипажының үз-үзен аямыйча эш алып баруы бушка китмәде.

Седовчылар үзләре суда актив рәвештә бару ритмына бик тиз кушылдылар. Бозлар арасында озак вакыт хәрәкәттә булганнан соң алар карабта тагын диңгез вахталарына күчтеләр. Флагман бозваткычы моряклары йөзендә өстәмә көч алган „Седов“ командасы палубада, кочегаркада, машина бүлегендә тырыш эш алып барды. Барсы да, ачык диңгезне, иркен киң дулкыннарны сагынган хәлдә, гаят зур энтузиазм белән эшләделәр. Ниһаят караблар Айсфиордка керделәр. Төш вактындагы томанлы караңгылык эчендә мәңгелек бозлар белән капланган, өзек-өзек булып тора торган, таулы ярлар күренде. „И. Сталин“ бозваткычының капитаны иптәш Белоусов парлы карванны фиордның бозлар белән капланган, куркынычлы һәм борылмалы фарватеры буйлап саклык белән һәм зур осталык белән алып барды. Тиздән алда Баренцбургның утлары күренде. Котып артындагы шәһәрнең халкы данлыклы седовчыларны һәм экспедициядә катнашучыларны гаят зур шатлык һәм горурлык белән каршылады. Караблар пристаньга килеп җиттеләр.

Хәзер тулы ход белән бункеровка бара, ә аннан соң тагын юлга, көньякка таба, кадерле һәм сөекле Ватан ярларына таба юнәләбез.

Чит илләрдә

Англия хөкүмәтенә Американың меморандумы

НЬЮ-ЙОРК, 24 гыйнвар. (ТАСС). АКШ ның дәүләт департаменты Англиянең АКШ тагы илчесенә 20 нче гыйнварда тапшырылган меморандумны иглан итте. Бу меморандумда дәүләт департаменты англичаннарны,—Гибралтарда Америка карабларын Италия карабларына караганда өч тапкыр озаграк тоталар, дип гаепли.

Меморандумда болай диелгән: „Кайбер хәлләрдә Америка карабларына, Америка законнарын бозып, йөк бушату өчен сугышучы илнең портына—Марсельгә юнәлергә туры килә, анда аларны карап чыгу өчен тагын тоткарлыйлар“.

Меморандумга Американың Гибралтарда 11 нче ноябрьдән 23 нче декабрьгә кадәр тоткарланган карабларының исемлеге беркетелгән.

Асоошиэйтед Пресс агентлыгының Вашингтон хәбәрчесенең сүзләренә караганда, дәүләт департаменты үзенең меморандумында Америка нотасына таяна. Бу нота Англиягә Американың Лондондагы илчесе Кеннеди тарафыннан тапшырылган һәм аның турында моңа кадәр әле бер нәрсә дә хәбәр ителгән булмаган.

Шулай итеп хәзер, соңгы ике ай эчендә АКШ ның Англиягә дипломатия тәртибендә биш тапкыр нота тапшырганлыгы маглүм булды.

Англичаннар Япония пароходын тентеделәр

ТОКИО, 22 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә, 12 сәгат 30 минутта, Япониянең АКШ тан Иокогамага баручы „Асама-Мару“ пароходы Япониянең территориаль суларында, Япония ярыннан 35,5 миль ераклыкта, Англия крейсеры тарафыннан туктатылган. Англия крейсерының моряклары „Асама-Мару“ бортына менеп, анда тентү ясаганнар. Карабта 51 немец булган, шуларның 21 е англичаннар тарафыннан крейсерга алып кителгән.

ТОКИО, 22 гыйнвар. (ТАСС). Япониянең чит ил эшләре министре урынбасары Тани Англия илчесе Крейгига, „Асама-Мару“ бортындагы немецләрне законсыз рәвештә кулга алуга каршы Япония хөкүмәтенең түбәндәге протестын тапшырган:

„Япония хөкүмәте Англиянең мондый хәрәкәтләрен Япониягә каршы дусларча булмаган акттан башка нәрсә итеп карый алмый һәм тотылган кешеләрнең кире җибәрелүен таләп итү хокукын үзендә калдыра“.

ТОКИО, 24 гыйнвар. (ТАСС). „Асахи“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Япониянең чит ил эшләре министре Арита кичә 9 сәгат 30 минутта Англиянең Токиодагы илчесе Крейгины чакырган һәм аның белән 30 минут беседа ясаган. „Асама-Мару“ пароходын тоткан Англия сугыш карабының законсыз хәрәкәтләренә каршы Арита протест белдергән. Арита болай дигән: „Англичаннар тарафыннан тотылган немецләрнең кире җибәрелүен таләп итү хокукын Япония үзендә калдыра, Япониянең башка пароходларына, ягни Япониягә кайту юлындагы „Ракуио-Мару“, „Гинио-Мару“, „Лаплста-Мару“ һәм „Татсута-Мару“ пароходларына килгәндә исә, Япония хәзер халыкара хокук нигезендә үз интересларын саклау өчен чаралар күрә. Бу фактка Англия флотының җидди игтибар юнәлдерүе кирәк“.

„Асахи“ газетасының хәбәр итүенә караганда, кичә Япония чит ил эшләре һәм диңгез эшләре министрлекләре вәкилләренең берләштерелгән утырышы да булган. Бу утырышта „Асама-Мару“ пароходы белән булган инцидент тикшерелгән. Утырыштан соң чит ил эшләре министрлегенә Англиянең Токиодагы илчелегенең советнигы Доддс чакырылган һәм аңа бу мәсьәлә буенча нота тапшырылган.

ТОКИО, 24 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Арита кабинетка, 21 нче гыйнварда кич белән Англиягә протест белдерелгәнлекне һәм англичаннар тарафыннан „Асама-Мару“ пароходыннан алынган 21 немецне кире кайтару таләбе бирелгәнлекне белдергән.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә Гаочен секторында сугышлар бара. Кытай гаскәрләре японнарны Суйчжоу районыннан Гаоченга таба чигенергә мәҗбүр иттеләр.

Көньяк Кытайда

Кантон—Самшуй һәм Кантон—Коулун тимер юллары зонасында кытай гаскәрләренең аерым отрядлары хәрәкәт итә. Кантоннан төньякта каты сугышлар бара.

Төньяк Кытайда

Ичэн районында японнар 3—4 мең кешелек гаскәр туплаганнар.

Шаньси провинциясенең көнбатыш өлешендә тынлык. Көньякта, көчле салкыннар һәм кар бураннары булуга карамастан, сугышлар дәвам итә.

Японнар Шаньси провинциясенең төньяк өлешеннән Баотоу районына шактый зур күләмдә көчләр күчерәләр.

Шахэ станциясе тирәсендә (Шаньдун провинциясе) кытай партизаннары тимер юл күперен шартлаттылар һәм японнарның Циндао—Цзинань тимер юлы буйлап бара торган гаскәри поездын һәлакәткә очраттылар. 18 вагон юкка чыгарылды. Японнарның бик күп солдатлары һәлак булды

***

Соңгы вакытта Кантонга японнарның тагын 3.500 яраланган солдаты һәм офицеры килде.

СУЙЧЖОУ ТИРӘСЕНДӘ КЫТАЙ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ЗУР ҖИҢҮЕ

ЧУНЦИН, 24 гыйнвар. (ТАСС). Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре зур җиңүгә ирештеләр. Суйчжоу секторында алар япон гаскәрләренең зур һөҗүмен кире кайтардылар. Кытай частьләре тиз арада японнарга каршы үзләре һөҗүмгә күчтеләр һәм кичә иртә белән Гаочэнны (Суйчжоудан төньякка таба 40 километрда) алдылар. Кытай гаскәрләре чигенеп баручы японнарны эзәрлекләп баралар.

Японнарның биредә сугыш алып барган 20 мең солдатларыннан шушындагы сугышта 4 мең кешеләре үтерелде һәм 7 мең кешеләре яраланды. Шулай итеп, бу участкыда хәрәкәт иткән япон гаскәрләренең 50 проценттан артыгы сафтан чыгарылды. Кытайлар тарафыннан сугышып алынган сугыш кораллары һәм кирәк-яраклары арасында 6 авыр орудие һәм 20 кыр орудиесе, шулай ук күп санда винтовкалар һәм пулеметлар бар.

Суйчжоу секторында японнарны тар-мар итү соңгы 7 ай эчендә Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләренең икенче җиңүе булып тора. Бу секторда кытайлар беренче тапкыр узган елның маенда җиңүгә ирешкәннәр иде, ул вакытта японнар уңышсыз һөҗүмнән соң, зур югалтулар биреп, Суйчжоуга таба чигенгәннәр иде.

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 24 гыйнвар. (ТАСС). Кичә көндез фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады, дип хәбәр ителә. Франция постларыннан берсе төнлә Лаутер елгасында Германия отрядының атакасын кире кайтарган.

БЕРЛИН, 23 гыйнвар. (ТАСС). Германиянең информация бюросы, Германия патрульләренең һәм удар частьләренең, тирән кар булуга карамастан, хәрби эшне дәвам иттерүләре турында хәбәр итә. Пирмазенстан көньяк-көнчыгышта бер патруль дошман линиясенә үткән һәм берничә артиллеристны пленгә алган. Бәрелеш вактында 3 француз үтерелгән, берничә француз яраланган.

БЕРЛИН, 24 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе Төньяк диңгездә Англиянең „Эксмаус“ дигән эсминецы юкка чыгарылды, дип хәбәр итә.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

24 нче гыйнварда барлык юнәлешләрдә розведчикларның эзләнүләре һәм вак пехота частьләренең бәрелешләре булды.

Безнең авиация разведка очышлары үткәрде.

В. В. КУЙБЫШЕВ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

КУЙБЫШЕВ, 24 гыйнвар. (ТАСС). Шәһәрдә, ялкынлы революционер-большевик В. В. Куйбышевның тормышына һәм эшенә багланышлы күп кенә тарихи истәлекләр сакланган.

Фрунзе исемендәге урамда элекке „Олимп“ театры йорты бар. Анда хәзер оперетта театры урнашкан. Йортның стенасында — „Бу йортта 1917 нче елның 8 нче ноябрендә Самарада Совет власты иглан ителде һәм Валериан Владимирович Куйбышев җитәкчелегендә беренче ревком сайланды“ дигән язу белән мемориаль такта куелган.

Чапаев исемендәге мәйданда хезмәт ияләре депутатларының өлкә советы башкарма комитеты йортында 1917 нче елны Самара ревкомы һәм Кызыл Гвардия штабы урнашкан булган. 1917 нче елның декабрендә биредә эшчеләр сыйнфына кабахәт рәвештә хиянәт итүчеләр — эсерчылар, ревком председателе В. В. Куйбышевның тормышына һөҗүм итеп, йортта шартлату ясаганнар һәм кызыл гвардиячеләргә мылтыклардан ут ачканнар. В. В. Куйбышев зарарланмаган.

Хәзер Куйбышев исме белән йөртелә торган урамда элекке „Триумф“ кино-театрының йорты сакланган. 1918 нче елның 8 нче декабрендә анда Самараның эшче яшьләренең беренче җыелышы булган һәм ул җыелышта В. В. Куйбышев катнашы белән шәһәрнең комсомол оешмасы төзелгән.

Арцыбушев урамында, хәрби-медицина академиясе тыңлаучыларының тулай торагы йортында элек Самараның губерния төрмәсе булган. Биредә 1916 нчы елның 18 нче сентябреннән 1917 нче елның февраль башына кадәр ялгызлар камерасында В. В. Куйбышев утырган. Ул Волга буе партия конференциясенең эше буенча кулга алынган булган. Хәзер камера элекке хәленә китерелә. Революция музее биредә В. В. Куйбышев истәлегенә күргәзмә оештырды.

Элекке труба заводының карт эшчеләреннән күп кешеләр В. В. Куйбышевны яхшы хәтерлиләр. 1916 нчы елда ул шушы заводта эшләгән. Хәзер Масленников исме белән йөртелә торган бу заводның цехларыннан берсендә фрезер станогы тора. Аңарга В. В. Куйбышевның портреты һәм: „1916 нчы елны 6 нчы номерлы цехта шушы фрезер станогында Валериан Владимирович Куйбышев эшләде“ дигән язу белән такта куелган.

Хәзер станокта стахановчы иптәш Куликова эшли. Ул ике сменалык норманы үти.

Шәһәрдә Куйбышев исемендә гүзәл культура сарае төзелде. Бу сарай алдына В. В. Куйбышевның бронзадан ясалган памятнигы куелды.

1940 нчы ел, 28 нче гыйнварда кич сәгат 6 да Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы) социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе ачыла.

Көн тәртибендә:

1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар. (Докладчы ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев).

Киңәшмәгә килүче делегатларны Казан вокзалында беренче номерлы залда Татнаркомзем дежурные каршылый.

Делегатларны регистрацияләү Татнаркомзем бинасында 16 нчы бүлмәдә үткәрелә. Телефоннар 8—15 һәм 32—20.

ОЕШТЫРУ КОМИССИЯСЕ.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПАРТИНФОРМАЦИЯ

ВКП(б) ның Сарман райкомы партинформация эшен шактый яхшыртты. Башлангыч партоешмалардан 29 коммунист партинформатор итеп тартылды. Бу иптәшләрнең партия эшендә тәҗрибәләре зур. Алар үзләренә йөкләнгән эшне яхшы итеп башкаралар. Информаторлар, булып үткән партҗыелышлар турында, партоешмадагы ялгышлыклар, колхоздагы кимчелекләр турында ВКП(б) райкомына язып торалар. Эштә булган кимчелекләрне бетерүдә райкомга ярдәм итәләр.

Мәсәлән, партинформаторлардан иптәш Монасыйпов „Комбайн" колхозы правление җитәкчеләренең җәмагат терлекчелеген үстерүгә тиешенчә игтибар итмәүләре, терлек азыгын әрәм-шәрәм итүгә юл куюлары, колхоз милкен туздыру фактлары турында күптән түгел генә райкомга информация бирде. Райком, бу эшне тикшерү өчен комиссия оештырды. Тикшерү нәтиҗәсендә, фактлар расландылар. Колхоздагы җитешсезлекләрне бетерү буенча һәм җавапсыз җитәкчеләргә карата конкрет чаралар күрелде, колхоз яңа кадрлар белән ныгытылды. Яңа җитәкчеләр колхоз хуҗалыгын яхшыртуда зур тырышлык күрсәтәләр.

Ләкин, ВКП(б) райкомының бу өлкәдә кимчелекле яклары да юк түгел әле. Ул кимчелекләрнең берсе итеп, информаторларга булышлык булмауны күрсәтергә кирәк. Информаторлар белән киңәшмәләр үткәрелми, аларның бурычлары турында беседалар оештырылмый. Шуңа күрә, кайбер информаторлар бу эшне тиешенчә аңлап җиткермиләр әле.

Г. Исламов.

СЕКРЕТАРЬЛАР КИҢӘШМӘСЕ

ВКП(б) ның Кукмара райкомы, ВЛКСМ райкомы белән берлектә, язгы чәчүгә хәзерлек турындагы мәсьәлә буенча партия һәм комсомол оешмалары секретарьларының киңәшмәсен үткәрде.

Киңәшмә колхозларда ефремовчы звенолар һәм стахановчылар мәктәбе төзү мәсьәләсен карады.

Киңәшмә, һәр колхозда ефремовчы звенолар һәм районда 18 колхозда стахановчылык мәктәпләре оештыру турында карар кабул итте.

Хәзер партия, комсомол оешмалары җитәкчелегендә, „Кызыл Сукачы", „Революция", „Ярыш № 1", „Ярыш № 2" һәм Ворошилов исемендәге колхозларда ефремовчы звенолар, „Азьлян", „Ярыш № 1" һәм Ворошилов исемендәге колхозларда стахановчылык мәктәпләре оештырылып эшкә башладылар.

Калган колхозларда да ефремовчы звенолар һәм мәктәпләр оештыру эше яхшы бара.

Ә. Солтанов.

ДЕПУТАТЛАР ПАРТИЯГӘ КЕРӘЛӘР

ВКП(б) ның Дөбъяз райкомы бюросы, шушы көннәрдә, Ташлы Кавал авыл Советы депутаты Гыйлаҗов, Саз авыл Советы депутаты Усманов, район Советы һәм шул ук вакытта Суксу авыл Советы депутаты Сафина иптәшләрне җирле Советларга сайлауларга хәзерлек кампаниясе вактында агитаторлар булып эшләүчеләрдән: Хайруллин (Ташлы Кавал авылы) һәм Бикмуллина (Суксу авылы) иптәшләрне ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул итте.

Әхмәдуллин.

Казан, мехкомбинатының партоешмасы комбинатның алдынгы кешеләре исәбенә үсә. 18 нче гыйнварда булган җыелышта 4 кеше ВКП(б) членлыгына кандидат итеп, 5 кеше ВКП(б) га член итеп кабул ителде.

ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алынганнар арасында—Казан Шәһәр Советы депутатлары Новикова һәм Мостафина иптәшләр дә бар. Шәһәр Советы депутаты Кикоть һәм район Советы депутаты Галиева иптәшләр кандидатлыктан членлыкка күчерелделәр.

(ТатТАСС).

Максим Горький исемендәге заводның алдынгы кешеләре партиягә керәләр. Партоешма 1939 нчы елны ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 37 кешене, ВКП(б) га член итеп 46 кешене кабул итте.

Яш коммунистлар производствода авангардлык үрнәкләре күрсәтәләр. Халитов, Биктагиров, Селезнов һәм Тригубов иптәшләр көнлек эш нормаларын 200 процент итеп үтиләр. *М. Халиков.*

ОЕШТЫРУ-ИНСТРУКТОРЛЫК БҮЛЕГЕНЕҢ ЭШЕ

ВКП(б) ның Зеленодольский шәһәр комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге 4 айдан бирле эшләп килә. Бу вакыт эчендә бүлек шактый эш тәҗрибәсе туплады.

Оештыру - инструкторлык бүлеге, эшли башлавының беренче көннәреннән үк, партиянең башлангыч оешмаларының эшләрен өйрәнүгә, партия хуҗалыгында тәртип урнаштыруга, партиягә кабул итү эшен яхшыртуга нык-лы игтибар бирде.

Бүлекнең инструкторлары партиягә кабул итү эшенә кайбер башлангыч партоешма секретарьларының игтибар биреп җиткермәүләрен ачтылар. Кайбер партоешмаларда рекомендацияләр биргән вакытта аерым коммунистлар тарафыннан ВКП(б) уставын бозу фактлары беленде. Мәсәлән, төзү комбинаты партия оешмасында коммунист иптәш Хәбибуллин, эштә бер елдан ким белүенә карамастан, иптәш Лагутинга партиягә керү өчен рекомендация биргән.

Максим Горький исемендәге завод һәм 3 нче номерлы фанер заводы партия оешмасында партиягә кабул итү эшенә җавапсыз караш фактлары булган. Максим Горький исемендәге заводның партия оешмасы И. дигән кешене партиягә кабул иткән. Соңыннан билгеле булганча, бу кеше партиягә кергәндә үзенең социал чыгышын яшергән. Ш. дигән кеше дә (фанер заводы партоешмасында) үзенең социал чыгышын яшергән.

Бүлек, башлангыч партия оешмаларының үсүенә һәм ныгуына аеруча нык игтибар бирә. Бүлек эшкә керешкән вакыттан алып, шәһәр комитеты 47 кешене ВКП(б) членлыгына кандидат итеп, 35 кешене член итеп кабул итте. Ике урында партиянең башлангыч оешмалары һәм фанер заводында 4 партгруппа төзелде.

Инструкторларның квалификациясен күтәрү өчен без 5 көнгә бер тапкыр тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре үткәрәбез. Киңәшмәдә инструкторларның эшләре тикшерелә, аерым җитешсезлекләргә анализ ясала һәм теге яисә бу мәсьәләне ничек итеп дөрес хәл кылу өчен практик киңәшләр бирелә.

Практика, оештыру - инструкторлык бүлегенең эше шәһәр комитетының барлык башка бүлекләре эше белән нык рәвештә бәйләнгәнлеген күрсәтә. Безнең инструкторларыбыз, башлангыч оешмаларның эшләрен өйрәнеп, җаваплы эшкә күтәрү өчен яш кадрлар барлыгын беләләр һәм бу иптәшләр турында кадрлар бүлегенә хәбәр итәләр. Кадрлар бүлеге, үз чиратында, аларны өйрәнә һәм кемне кая күтәрү кирәклеге мәсьәләсен хәл итә. Безнең бүлекнең инструкторлары, теге яисә бу партоешмада идея-тәрбия эшләренең түбән дәрәҗәдә торганлыгын белеп, бу турыда мәсьәләне пропаганда һәм агитация бүлеге алдына куялар. Алар, шәһәр комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге работниклары белән берлектә, бу җитешсезлекләрне бетерүгә ирешәләр.

Безнең бурычыбыз—партиянең башлангыч оешмалары белән элемтәне тагын да киңәйтүдән һәм ныгытудан, җитәкчелегебезнең сыйфатын һәр яклап яхшыртудан гыйбарәт.

М. Сусликов.

ВКП(б) ның Зеленодольский шәһәр комитетының оештыру - инструкторлык бүлеге мөдире.

Лаиш районы „Путь Ленина" колхозы партоешмасында. ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомының „Колхозларда бөртекле культураларның сортлы чәчүлекләрен планлаштыру турында"гы карарын тикшерүгә багышланган җыелыш. РӘСЕМДӘ: башлангыч партоешма секретаре Я. П. Маденов карарны укый.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ФИДЕИЗМ НӘРСӘ УЛ

ВКП (б) ның Молотов райкомы пропагандисты иптәш Сафиуллинның „фидеизм нәрсә ул" дигән соравына җавап итеп түбәндәге мәкаләне урнаштырабыз.

„Фидеизм" сүзе латыйнча „фидес" дигән сүздән алынган һәм ул дингә ышану мәгънәсендә килә. Үзенең эчтәлеге ягыннан фидеизм—караңгылыкка өндәүдән, фәнгә караганда динне өстен күрүче реакцион, дини карашларны пропагандалаудан гыйбарәт.

Фидеизмга өндәүнең характерлы үрнәге итеп, Америкаиың попчы философы В. Джемсның (1842—1910 еллар) фикерләрен китереп үтәбез. Ул болай дип язды: Алла турындагы һәм мәңгелек тормыш турындагы мәсьәләләр „безнең логикабыз (фикер йөртүебез) белән түгел, бәлки безнең ышануыбыз белән хәл ителәләр. Мин нинди булса да логиканың минем ышануымны тыярга хакы юк дип саныйм". (В. Джемс „Прагматизм", бит 18).

Логиканы һәм гомумән фәнне богаулау попларга хезмәт ияләрен дин каршында куркуда тоту һәм аларның башларын дин белән агулау өчен кирәк.

Фидеизм урта гасыр схоластикасы заманнарында ук башланган, ул вакытта философиягә дин хезмәтчесе роле бирелә иде. XIX нчы йөзнең икенче яртысында фидеизм яңадан шактый киң җәелде. Буржуазия, үзенең элеккеге революционлыгын югалткач һәм тәмам реакцион сыйныф булып әверелгәч, массаны рухани яктан кол итү коралы булган дингә тотынды. Дин белән фәнне килештерергә омтылучы философлар һәм „галимнәр"—фидеистлар килеп чыгалар. В. Джемс һәм Карус (Америка), Э. Бутру (Франция), Корнелиус (Германия), К. Пирсон (Англия),—менә аеруча атаклы фидеистлар шулар.

Үзләрен прагматистлар дип (В. Джемс), модернистлар дип (Э. Бутру), эмпириокритицистлар дип (Мах, Авенариус, Пирсон) атап алар барсы да теологиянең өйрәтелгән приказчиклары, капиталистларның турылыклы хезмәтчеләре булдылар. Үзләренең гаять реакцион тагълиматлары белән алар „халыкны дини әфиүн белән исертәләр" (Ленин, том XIII, бит 185).

Патша Россиясендә фидеизмга каршы көрәш, аның контрреволюцион, попчылык асылын фаш итү караңгы Столыпин реакциясе елларында аеруча актуаль булып әверелде. Бу вакытта патша реакциясе революцион эшчеләрне рәхимсез җәзалау белән бергә, идеология фронтында да һөҗүм алып барды.

Буржуазия, меньшевиклар, эсерлар һәм „үзләрен марксистлар дип санап та, марксизм позицияләрендә бер вакытта да нык тормаган партияле интеллигентларның"(„ВКП(б) тарихы", бит 114) кайбер өлеше—Богданов, Базаров, Луначарский,—„бер уртак максатны—массаларны революциядән биздерүне" (шунда ук) күздә тотып, марксизм - ленинизм партиясенең дөньяга карашына каршы, коммунизмның теоретик фундаментына—диалектик һәм тарихи материализмга каршы ярсулы көрәш алып бардылар.

Махчыларның ялган фәнни карашларын эзлекле рәвештә фаш итеп, Ленин, аларның дингә карата „партиясезлек" һәм нейтральлек битлекләрен алып ташлады һәм аларның ачыктан-ачык фидеизм ялчылары, аның лакейлары булып эш итүләрен күрсәтте. Ленин болай дип язды: „Эмпириокритицизмның объектив, сыйнфи роле тулысы белән фидеистларның гомумән материализмга каршы һәм аерым алганда тарихи материализмга каршы көрәшләрендә аларга хезмәт күрсәтүгә кайтып кала" (Ленин, том XIII, бит 292).

Махчыларның „теория" се безнең аңыбыздан тыш һәм аңа бәйсез рәвештә яшәүче объектив дөньяның барлыгын инкар итүгә нигезләнгән. Асылда махизм Англия епископы Беркли (1684—1753) тагълиматын кабатлый. Беркли, дөньяда кешенең сизүеннән тыш яши торган бер нәрсә дә юк дип санады, ул: „минем әйләнәмдәге нәрсәләр барсы да—алар минем аңым тудырган нәрсәләр генә" диде. Беркли бу кагыйдәгә бары тик алланы гына кертми.

Беркли үзенең субъектив—идеалистик тагълиматын материализмга каршы юнәлдерде. Ул, динне ныгыту өчен материализмны җимерергә омтылуын ачыктан-ачык белдерде.

Беркли үзенең материализмга каршы походының сәбәпләрен ачыктан-ачык икрар иткән булса, Мах, Авенариус һәм аларның иярченнәре исә Беркли идеяләрен бутап, яшрен формада үткәрәләр. Алар да материянең объектив реаль төстә, кешегә бәйсез рәвештә яшәвен инкар итәләр. Мах болай дип язды: „Безнең материя дип атый торган нәрсәбез бары тик **элементларның** („сизүләрнең") маглүм законлы элемтәсе ул" (Ленин буенча китерелде, том XIII, бит 119).

Материаль дөньяның беренчел икәнлеген инкар итүче һәм аны табигаттән югары тора торган көч барлыкка китергән дип иглан итүчеләрнең—фән дошманнарының, барлык идеалистларның нигезе нак менә шушы. Берәүләр бу көчне турыдан-туры алла дип, икенчеләре — мәсәлән, Гегель, абсолют идея дип атыйлар, өченчеләр исә—субъектив идеалистлар—аны кешенең үзенең аңы итеп күрсәтәләр. Ләкин моның белән аның асылы үзгәрми.

„Фидеизм „сизелә торган дөньядан тыш" нәрсәдер (ягни алла.— С. К.) бар ди. Табигать фәне белән риза булган материалистлар моны кискен рәвештә кире кагалар" (Ленин, том XIII, бит 95).

Хәзер безнең кулда булган табигать белеме маглүматлары аң материядән алда килә дип иглан итүче фидеистларның һәм идеалистларның барлык уйдырмаларын фаш итәләр. Табигать белеме, җирнең кеше дә, гомумән һичбер төрле җан иясе дә булмаган һәм була да алмаган вакытта ук булганлыгын күрсәтә.

„Органик материя—ул, соңрак булган күренеш, озакка сузылган үсешнең җимеше. Димәк, сизүче материя булмаганда,—берниндн „сизүләр комплексы" да булмаган,—Авенариус тагълиматы буенча, имештер, әйләнә-тирә белән „аерылгысыз" бәйләнгән бер нинди мин булмаган. Материя—ул, беренчел,—фикер, аң, сизү—югары үсеш продукты. Табигать белеме стихияле төстә нигезләнә торган материалистик тану теориясе әнә шундый". (Шунда ук, бит 61).

Шулай итеп, Ленин, хәзерге заманның табигать белеме маглүматларына таянып, махчыларның, тышкы дөнья, имештер, кешенең аңында гына бар дигән субъектив идеалистик карашларын фаш итте.

Фидеизмның турылыклы ялчылары буларак, махчылар попларның дөньяны алла яраткан дигән саташуларын фәнни сөйләнүләр белән капларга маташтылар.

Философиянең төп мәсьәләсен идеалистик юл белән хәл итү, дөньяның материаль булудан гыйбарәт булган бердәмлеген фикер йөртүдән, алладан, рухтан китереп чыгару, табигатнең безнең сизүләребезнең чыганагы икәнлеген инкар итү туп-туры агностицизм, ягни тышкы дөньяны сизү мөмкин түгел дип караудан, объектив хакыйкатне инкар итүгә алып бара.

Динне фәннән өстен күрүче философия поплары, реакционерлар дөньяны танырга мөмкин булмагач, димәк, җәмгыятьне үзгәртеп корырга омтылырга да ярамый дип хезмәт ияләрен ышандырырга маташтылар һәм маташалар. Без тышкы дөнья үсешенең законлылыгын төшенеп белә алмыйбыз икән, без аңа йогынты да ясый алмыйбыз. Моннан кешеләр аңа пассив төстә яраклашырга һәм тормыштагы барлык авырлыкларга, изелүгә, капиталистик коллыкка түзәргә тиешләр дигән нәтиҗә чыга.

Сизү органнарының күрсәтүләренә ышанулары һәм дөньяга безнең тәҗрибәбездә бирелгәнчә караулары турындагы махчыларның барлык декларацияләре—ялган. Махчылар дөньяны, андагы тавышларны, исләрне, буяуларны чын объектив дөнья дип карамыйлар. Алар аны бары тик үзләренең шәхси сизүләренең комплексты гына дип карыйлар. Андагы чын сизүләр чыганагын—объектив реаллыкны—алар кире кагалар. Димәк, махчылар безнең сизү органнарыбызның күп төрле чын дөньяның, табигатнең, җәмгыятьнең объектив барлыгын исбат итә торган күрсәтүләренә ышанмыйлар.

Менә шуңа күрә дә махчылар—алар, субъективистлар, агностиклар. „Алар сизүләрдә бу объектив реаллыкның дөрес рәсмен күрмиләр, табигать белеменә турыдан-туры каршы киләләр һәм фидеизмга юл ачалар. Киресенчә, материалист өчен дөнья күренгәнгә караганда баерак, җанлырак, күп төрлерәк, чөнки фән үсешенең һәрбер адымы аңарда яңа якларны ача" (Ленин, том XIII, бит 105).

Әле кичә генә танылмаган нәрсә булган әйберләр, яки, XVIII нче йөзнең немец философы И. Кант әйткәнчә, „әйбер үзе өчен" булган нәрсәләр бүген, практикага таяна торган фән ярдәме белән, танылган әйбер булып, безнең өчен булган әйбер булып әвереләләр. Папанинчылар экспедициясенә кадәр Төньяк котып кешелек дөньясы өчен серле иде. Безнең Котып геройларыбызның боз өстендә кышлаулары котыпның серен ачты.

Фидеизм буржуаз фәндә һәм буржуаз философиядә хәзерге вакытта да яшәп килә. Капитализмның черүе, буржуаз культураның үлә баруы, буржуазиянең үзенең алдагы көненнән куркуы капиталистик илләрдә диннең һәм мистицизмның җәелүенә уңайлы шартлар тудыралар.

Дин һәм чиркәү изүеннән, идеализм һәм фидеизм томаныннан азат булган алдынгы фәннең, иске традицияләрне кыю рәвештә ватучы һәм бөтен дөньяны революцион төстә үзгәртеп коруга алып баручы фәннең чәчәк атуы өчен бары тик Советлар Союзында гына барлык шартлар тудырылган.

(С. Колесникова мәкаләсеннән).

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

Пропаганда мәсьәләләрен киң яктыртырга

Марксизм-ленинизм идеясен пропагандалау эшендә большевистик матбугат хәл иткеч роль уйный. Шуңа карамастан, кайбер газеталар моңа тиешле әһәмият бирмиләр.

Менә безнең алда, ВКП(б) ның Алабуга райкомы органы „Сталин юлы" газетасының 1939 нчы елгы комплекты. Без аның башка якларына кагылмыйча, бары тик пропаганда мәсьәләләрен яктырту эшенә генә тукталабыз.

Бөтен ел буена газетада партия пропагандасы буенча барлыгы 15 материал урнаштырылган. Болар эченә түбәндәге материаллар керәләр: „Россиядә крепостной хокукы ни өчен бетерелде", „Народникларны тар-мар итү", „Экономистлар Россиядә бердәм политик партия төзүнең төп дошманнары", „Лениннең „Бер адым алга, ике адым артка" дигән китабы турында", „Дәүләтнең килеп чыгуы", „Җитештерүче көчләр һәм җитештерү мөнәсәбәтләре һәм җәмгыятьнең үсешендә аларның роле" һәм башка шуның кебек материаллар.

Районда пропаганда эшенең торышы, ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләрнең тәҗрибәләрен уртаклашу мәсьәләләренә карата ел буена бары 4 материал урнаштырылган. Аларның берсе—„ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә тиешле ярдәм юк" (16 февраль), икенчесе—„ВКП(б) тарихын өйрәнү өстендә мин ничек эшлим" (30 май), өченчесе—„Мин ВКП(б) тарихын ничек өйрәнәм" (30 сентябрь), дүртенчесе—„Партия пропагандасына җитәкчелекне көчәйтик" (18 октябрь) дигән мәкаләләр. Менә бар булган материал шуннан гыйбарәт. Алар да бик өстән, гомуми фразалар белән генә язылганнар. Мәсәлән, „ВКП(б) тарихын өйрәнү өстендә мин ничек эшлим" дигән мәкаләдә ТБУМ укытучысы иптәш Мәүлюдов болай дип яза: „Мин иң элек „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н ашыкмыйча гына бер кат укып чыктым. Аннан соң һәрбер бүлегең аерым рәвештә өйрәнә башладым. Бу вакытта инде мин ярдәмче материаллардан файдаландым. ВКП(б) тарихын өйрәнүдә матур әдәбият уку да нык ярдәм итә".

Иптәш Мәүлюдовның бу мәкаләсе башкаларга үрнәк күрсәтү максаты белән язылган, әлбәттә. Шулай булгач, ярдәмче материаллардан файдалану дип кенә түгел, ә һәрбер бүлек буенча аның нинди материаллар укуы һәм матур әдәбияттан нәрсәләр укуын да күрсәтү кирәк иде.

Югарыда әйтеп үткәнчә, газета пропаганда мәсьәләләрен онытканда бер генә искә ала. Үткән елның февраль башыннан алып май ахрына кадәр булган вакыт эчендә пропаганда турында бер генә материал да урнаштырылмаган. Марксизм-ленинизм өлкәсендә төп белемнәр энциклопедиясе булган „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" басылып чыгуга бер ел тулу уңае белән газета баш мәкалә бирү белән генә чикләнгән. Пропаганда мәсьәләләренә карата ел буена бер генә баш мәкалә бирү (ул да ТАСС мәкаләсе) үзе генә дә пропаганда мәсьәләсенә бу газетаның тиешле әһәмият бирмәвен ачык күрсәтә.

Дингә каршы пропаганда мәсьәләсенә килгәндә, бу газетада эш тагын да начар тора. Бер ел эчендә дингә каршы пропаганда мәсьәләсе буенча барлыгы ике материал урнаштырылган: аның берсе—„Дингә каршы пропаганданы киң җәелдерик", икенчесе—„Дин турында Ленин" дигән мәкалә. Бу мәкаләләрнең икесе дә „Кызыл Татарстан" газетасыннан алынып басылганнар.

Пропаганда мәсьәләләре буенча тематика гаять бай, тик аны оештыра белергә генә кирәк. Мәсәлән, башка районнардагы кебек үк, Алабуга районында да партияле һәм партиясез йөзләрчә большевиклар марксизм-ленинизм теориясен, большевиклар партиясенең гүзәл тарихын үзлекләреннән өйрәнәләр. Алар арасында хәзер инде „Кыскача курс"ның VIII, IX нчы бүлекләрен өйрәнүчеләр һәм „Кыскача курс"ның барлык бүлекләрен өйрәнеп, марксизм-ленинизм классикларының аерым әсәрләрен тирәнтен өйрәнү өстендә ныклап эшләүчеләр аз түгел. Бу иптәшләрнең тәҗрибәләрен газетада яктырту башкаларга зур булышлык итәр иде.

Пропаганда мәсьәләләрен яктырту буенча мондый кимчелекләр күп кенә район газеталарына кагыла. Газеталарның гаять күпчелеге озын-озын материаллар урнаштыру белән мавыгып, районда пропаганда эшенең торышына аз әһәмият бирәләр. Үткәрелә торган лекция һәм докладлар турында язганда, еш кына, аларда фәлән кадәр кеше катнашты, фәлән кадәр сораулар бирелде кебек гомуми сүзләр белән чикләнәләр. Лекциянең, докладның ничек үтүе, аның сыйфаты турында язмыйлар.

Групповой һәм индивидуаль консультацияләр, теоретик конференцияләр, тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре, аларның уңышлы һәм уңышсыз яклары турында, парткабинетларның эшләре турында газеталар системалы рәвештә язып торырга бурычлылар.

Районның җитәкче активы үзенең теоретик белемен күтәрү өстендә ничек эшли? Аларның үрнәк булырдай тәҗрибәләрен газета аркылы уртаклашырга һәм үзенең идея - политик белемен күтәрүдә эшләмәүче аерым иптәшләргә карата җәмагатчелек фикерен тупларга кирәк. Ниһаять, газета работниклары пропаганда эше белән үзләре яхшы таныш булырга һәм үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшләргә тиешләр. Шуннан башка пропаганда мәсьәләләрен газета битләрендә тулы яктырту, әлбәттә, читен булачак.

Партия райкомнары, бигрәк тә аларның пропаганда һәм агитация бүлекләренең работниклары пропаганда мәсьәләләрен яктырту эшенә җидди игтибар бирергә, бу эштә газетага якыннан торып булышлык итәргә тиешләр.

Югары уңыш алу өчен ефремовчыларча эшләргә

Югары уңыш алу—ул безнең кулда

Әйе, безнең кулда. Моны соңгы еллардагы практика ачык күрсәтә. Без 1937—1938 нче елларда һәр гектардан уртача 16,5 центнер уңыш алдык. Шул уңыш аркасында безнең „Кызыл Сабанчы“ колхозы үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә экспонент булып катнашты. Күргәзмәнең Баш Комитеты икенче дәрәҗә диплом белән, 5.000 сум акча һәм 1 мотоцикл белән бүләкләде. Һава шартларының бер кадәр коры булуына карамастан, 1939 нчы елда да югары уңыш алдык.

Мондый уңыш алуга ирешүне безгә нәрсә тәэмин итте соң? Җирне агрономия кагыйдәләренә туры китереп эшләү һәм уңыш өчен көрәшкә колхозчылар массасын туплау. Без быел тагын да югары уңыш алу өчен көрәшәбез. Сталинград өлкәсе йөзпотчыларының һәм Калинин районы алдынгыларының мөраҗәгатенә кушылып, без конкрет йөкләмәләр алган идек. Колхозчылар ул йөкләмәләрне үтәүдә җиң сызганып эшлиләр.

Тунга сөрүне 22 сантиметр тирәнлектә итеп үткәрдек. Кар тотуны беренче кардан ук башладык. Карны кырда тоту белән генә чикләнмибез, авыл эчендәге, чокырлардагы карларны басуның ачык урыннарына ташыйбыз. Беренче тапкыр тотылган кар өемнәре тигезләнеп җиткәч, карны икенче тапкыр тота башладык. Шулай итеп, тунга, сөрелгән, яхшы итеп эшләнгән басуларда карның калынлыгы урны-урны белән 70—80 сантиметрга җитә.

Безнең колхозның чәчү орлыклары беренче сортлы итеп чистартылды. Чәчү алдыннан орлыкларны агулау, яровойлаштыру үткәреләчәк. Без иртә чәчеләчәк культураларны чәчүне өч-дүрт көндә һәм соңгы культураларны ике көндә төгәлләүне күздә тотабыз. Язгы чәчүне уңышлы үткәрү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Бөртекле чәчүлек орлыклары ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарларына туры китереп җитәрлек төрдә хәзерләнде. Чәчкечләр, сабаннар, тырмалар, арбалар, сбруйларга яхшы сыйфатлы ремонт үткәрелде.

Агротехника түгәрәкләрендә занятиеләр биш көн саен үткәрелә. Колхозчылар монда зур кызыксыну белән укыйлар, югары уңыш алуны арттыру, ефремовчыларча эшләү юлларын өйрәнәләр. Түгәрәктә йөрүчеләрдән Рәшидә Туктарова, Фатыйма Әхмәдуллина һәм Факиһә Әхмәдуллина иптәшләр үткән темаларны отлично билгесенә үзләштерделәр. Кырга тирес чыгару һәм урындагы ашламаларны җыю эше яхшы бара.

Язгы сәчүгә хәзерлек һәм югары уңыш алу өчен ефремовчыларча эшләү безнең колхозда әнә шулай тора.

Гыйззәтулла Усманов.

Буденный районы, „Кызыл Сабанчы“ колхозы председателе.

УҢЫШНЫ ЯУЛАП АЛЫРГА КИРӘК!

Һәр гектардан кимендә 100 пот иген уңышы алу турында Сталинград өлкәсе алдынгыларының чакыруын безнең колхоз членнары гаять зур күтәренкелек белән каршы алдылар. Үзебездә булган мөмкинлекләрне җентекләп тикшергәннән соң, без һава шартларының нинди булуына карамастан, һәр гектардан уртача 120 пот, ә аерым участкылардан 150 шәр пот уңыш алырга йөкләмә алдык.

Бу йөкләмә тулысынча үтәлерлек. Мин моны үзебезнең колхоз практикасында беләм. Агротехника чараларын вактында һәм дөрес үткәрү нәтиҗәсендә, безнең колхоз соңгы ике елда ел саен һәр гектардан 14,22 центнер уңыш алды. Шулай итеп, без һава шартларына гына ышанып торырга ярамавын, нык иген уңышы алу өчен җидди көрәш кирәклеген үз тәҗрибәбездә күрдек.

Югары уңыш өчен көрәш көздән үк башланды. Быел яз чәчеләчәк участкылар барсы да яхшы сыйфатлы итеп тунга сөрелде. Кар тотуга хәзерлекне дә көз көне башладык. Хәзер безнең барлык чәчү мәйданыбызда да кар тотылган.

Колхоз язгы чәчүгә хәзер. Чәчкечләргә, сабаннарга, культиваторларга һәм тырмаларга ремонт ясауны җирле Советларга сайлаулар көненә төгәлләдек. Тимерче иптәш Арзаматов норманы системалы рәвештә арттырып үтәде, иске частьләрдән киң файдаланды.

Ат транспорты, сбруйлар тулы хәзерлектә. Атлар барсы да урта көрлектә; атлар өчен кирәкле азыкны бөтен чәчү чорына җитәрлек күләмдә аерып куйдык.

Чәчү орлыклары чистартылган; алар коры урында сакланалар. Орлык чистартуда иптәш Филекова звеносы стахановча эш үрнәкләре күрсәтте.

Бездә һәрбер колхозчы язгы чәчү вактында үзенең эш урнын, нинди эш башкарачагын яхшы белә. Атлар һәм инвентарь аерым колхозчыларга беркетелгән. Чәчкечләрне тәҗрибәсе аеруса зур булган иптәшләргә беркеттек. Мәсәлән, колхозчы К. Арзаматов чәчү эшендә быел 10 нчы ел эшләячәк.

Язгы чәчү вактында җәмагат туклануы оештырабыз. Моның өчен колхозчыларның гомуми җыелышы кирәкле продуктларны билгеләп куйды.

Безнең колхоз бөртекле культуралар буенча да һәм терлекчелек күрсәткечләре буенча да Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуга кандидат булып тора. Без күргәзмә ачылуны зур уңышлар белән каршылау өчен, аерым участкылардан гына түгел, барлык чәчү майданыннан югары иген уңышы алуны тәэмин итү өчен көрәшәбез.

С. Лягаев.

Чаллы районының „Нива“ колхозы председателе.

Күтәрелеш

Норлат районының күп кенә колхозлары йөзпотчылар ярышына кушылганнан соң язгы чәчүгә хәзерлек эшен яхшырттылар. Югары иген уңышы алуда рекорд бирүче Ефремов, Чуманов һәм башка иптәшләрнең эш тәҗрибәләренә таянып, 11 колхозда „Йөзпотчылар мәктәбе“ исемендә түгәрәкләр оештырылды. Түгәрәкләрдә занятиеләр вактында үткәреләләр. Колхозчылар занятиеләргә зур кызыксыну белән йөриләр. 11 колхоздагы түгәрәкләрдә 480 кеше укый.

Ленин исемендәге колхозда беренче занятиеләрдән соң ук барлык бригадалар йөзпот иген уңышы алу өчен үзара социалистик ярыш договорлары төзеделәр. Түгәрәктә 85 стахановчы укый. Алар арасында звено башлыклары һәм бригадирлар бар. Түгәрәктә укучы һәрбер кеше алган белемен практик тормышка ашыра. Чәчү орлыклары хәзерләү, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау яхшы сыйфат белән төгәлләнде. Ремонттан чыккан барлык машиналар акт белән кабул ителде. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда Р. Мифтахов, С. Салаватовлар көнлек норманы 130—145 процент үтәп бардылар. 3 нче һәм 4 нче бригадалар (бригадирлары Әхметшин һәм Яров) бишәр гектар җирдән 45 әр центнер уңыш алу өчен йөкләмә алдылар. Алар алган йөкләмәләрен тулы үтәү өчен ныклы эш алып баралар. Кош тизәге җинау планы 100 процент, басуга тирес чыгару, көл һәм фекали җыю эшләре 75 әр процент үтәлде инде. Быел басуга 2.000 тонна чамасы торф чыгарылачак.

Ленин исемендәге колхоз белән ярышучы „Көчле Ирек“ колхозында да язгы чәчүгә хәзерлек эшләре кызу темп белән бара. Биредә дә колхозчыларның агротехник белемнәрен күтәрү өчен йөзпотчылар мәктәбе—түгәрәк оештырылды. Беренче занятиедә: „Мул иген уңышы алуда ефремовчылар звеносының агротехника чаралары“ дигән темада лекция укылды. Лекцияне район парткабинет мөдире иптәш Яһүдина укыды.

Бу занятиедә чыгып сөйләүче иптәшләрдән 3 нче бригада бригадиры Х. Хөсәенев болай диде:

— Без 1939 нчы елда мул иген уңышы яулап алдык. Гектарыннан уртача 16,54 центнер уңыш алуга ирештек. Без быел тагын да зуррак уңышларга ирешербез. Без инде басуга 694 йөк урнына 1.200 йөк тирес чыгардык, 150 тонна торф хәзерләү урнына 157 тонна хәзерләдек, 17 центнер урнына 21 центнер кош тизәге җинадык. 3 гектар җирне яхшы эшкәртеп, аннан 45 шәр центнер бодай уңышы алырга сүз бирәбез.

Шулай ук башка бригадалар да конкрет йөкләмәләр алып, социалистик ярышка чыктылар.

М. Гыйсмәтуллин.

Биектау районы, Буденный исемендәге колхоз стахановчылары, сулдан уңга: А. С. Рязанова һәм Е. М. Кольцова иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

ФЕРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН— ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНӘ!

ЯРЫШКА КУШЫЛАБЫЗ

(Телефон буенча үз хәбәрчебездән)

„13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгате Әлмәт районы колхозчылары тарафыннан зур күтәренкелек белән каршыланды. „Дирижабль“ артеле колхозчылары бу мөраҗәгатне үзләренең гомуми җыелышларында тикшерделәр. Җыелыш алдынгы колхозчылар инициативасына бердәм рәвештә кушылды. Бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә болай диелә:

— Иптәш Сталин исемендәге Зур Ферганә каналын төзү тәҗрибәсен юл төзелешендә куллану өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Бу эшне тик оештыра белергә генә кирәк. Казан—Бөгелмә трактының 7 километрын төзекләндерү эше безнең колхозга төшә. Бу эшне без зур шатлык һәм намус белән башкарачакбыз. Без юл төзү участкыларына 610 кубометр чуер таш чыгардык инде.

Калган төзү материалларын хәзерләүне 1 нче мартка төгәлләүне ышандырабыз. Юлларны ремонтлау һәм канаулар чистарту эшен, шулай ук пассажирларга ял итү өчен бер урында культуралы павильон һәм юл буена 2.000 данә агач утырту эшен 1 нче майга төгәлләргә сүз бирәбез.

„Дирижабль“ колхозы членнары Әлмәт авылының Сталин исемендәге колхозын социалистик ярышка чакырдылар. Ярышның беренче көнендә үк колхозның мактаулы стахановчылары Зариф Шәкуров һәм Рамазанов иптәшләр төзү материаллары ташу эшендә көнлек нормаларын 200 процент итеп үтәделәр. „Дирижабль“ колхозы белән үзара ярышып эшләүче „Илкам“ колхозы членнары төзү материлларын хәзерләү планын 40 процент үтәделәр дә инде. Бу эштә Хәбибрахманов һәм башка иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Алар көнлек норманы әледән-әле арттырып үтиләр.

„Туры Юл“ колхозы членнары (председателе иптәш Зарипов) гүзәл эш үрнәкләре күрсәтәләр. Төзү материаллары хәзерләү планын колхоз 82 процент үтәде. Бу колхозның стахановчысы иптәш Нуркаев көнлек норманы 200—250 процентка җиткереп үти. Харисов һәм башка иптәшләр дә нормаларын арттырып үтиләр.

Район колхозларында төзек һәм культуралы юл өчен социалистик ярыш көннән-көн киң колач ала. Төзү материалларын юлларга чыгару планы район буенча 15 нче гыйнварга 47 процент үтәлгән.

З. Салахетдинов.

БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

Столбище районының „13 лет Октября“ артеле колхозчылары Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү хәрәкәтенең инициаторы булдылар. Алар Казан—Чистай—Бөгелмә трактын төзекләндерү буенча республикабызның 10 районын социалистик ярышка чакырдылар. Бу трактның экономик әһәмияте гаять зур.

Дөресен әйтергә кирәк: районыбызның партия һәм совет оешмалары юл төзелеше эше белән моңа кадәр һич канәгатьләнерлек шөгыльләнмәделәр. Бу өлкәдә без аерым хәлләрдә юл төзелеше работникларының докладларын тыңлау белән генә чикләндек. Ә юл төзелеше турында үз карарларыбызның үтәлешен тикшерүне оештырмадык. Шуның нәтиҗәсендә, районыбыз юл төзелеше эшендә берничә еллар буена артта калып килә. Столбище—Нарманка һәм Столбище—Казан юллары хәзергәчә ташландык хәлдә яши. Атлар белән дә һәм автомашиналар белән дә үтүе кыен.

„13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгатен без ВКП(б) райкомы һәм район башкарма комитеты утырышында тикшереп, юл төзелеше буенча дәүләт планын үз вактында тулы үтәүне тәэмин итү өчен конкрет чаралар билгеләдек. Хәзер һәрбер колхозда юл төзелеше бригадалары оештырабыз. Аларны тарту көчләре һәм эш инструментлары белән тәэмин итәбез. Мондый бригадалар күпчелек колхозларда оештырылды да инде.

22 километр юлны төзекләндерү—безнең алда җаваплы һәм мактаулы бурыч булып тора. Моның өчен безгә эш объектларына 13 мең кубометр төзү материалларын ташырга кирәк. Бу эшне үз вактында башкару өчен көндәлек эшкә 350 ат билгелибез. Төзү материалларын ташуны 20 нче марттан да соңга калмыйча төгәлләячәкбез. Юл төзелеше эшендә алдынгылыкны яулап алган колхозларны һәм юл төзелеше стахановчыларын бүләкләү өчен махсус фонд билгеләдек. Иң алдынгы колхозга ВКП(б) райкомының һәм район Советының күчмә кызыл байрагы тапшырылачак.

Хәзер районыбызның һәрбер колхозында җыелышлар үткәрелә. Бу җыелышларда Чкаловск трактын төзекләндерү турында „13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгате тикшерелә һәм алда торган эшләрне башкару буенча конкрет чаралар билгеләнә.

Район яшьләре юл төзелешенә карата аеруча зур активлык күрсәтәләр. 200 комсомолец юл төзелешендә эшләргә теләкләрен белдерделәр. Шулардан 40 кеше бригадирлар һәм 30 кеше политик-масса эшләрен оештыручылар булып эшләячәкләр. Юл төзелеше эшләренә көндәлек җитәкчелек итү өчен ВКП(б) райкомы янында 5 кешелек комиссия төзедек.

Бу әле беренче адымнар гына. Без үз өстебезгә алган йөкләмәләребезне намус белән үтәп чыгачагыбызга нык ышанабыз.

Чкаловск трактын төзекләндерү эшенә башка районнар да кушылырга һәм бу гаять җаваплы эшне партия, совет оешмаларының җитәкчеләре үз кулларына алырга тиешләр. Төзек юллар өчен социалистик ярыш байрагын тагын да югары күтәрик!

С. Петров.

ВКП(б)ның Столбище райкомы секретаре.

НАМУСЛЫ ХЕЗМӘТ ҖИМЕШЛӘРЕ

Колхоз правлениесе халык белән шыгрым тулы. Монда картлар да, яшьләр дә бар. Алар шат, алар көләч йөзлеләр. Коллективның игътибары радиорупорда. Алар радио аша тапшырыла торган соңгы хәбәрләрне зур кызыксыну белән тыңлыйлар...

Сәгат көндезге 12. Шәһәрдән килгән лектор Финляндия фронты турында беседасын башлады. Кешеләрнең күзләре стенага таба, Европаның физик һәм политик карталарына таба текәлде.

Лекторның һәрбер сүзе тыңлаучыларда зур кызыксыну тудыра. Героик Кызыл Армиябезнең гүзәл хәрәкәтләре, фин халкын кан эчкеч Маннергейм бандаларыннан азат итү өчен героик көрәш эпизодлары тыңлаучыларда тирән шатлык хисләре тудыра. Бу көрәштә үзләрен кайнар патриот итеп танытkan, Ватан өчен, бөек Сталин өчен актык тамчы каннарын да бирергә хәзер торган илебезнең батыр уллары бер-бер артлы күз алдына килеп басалар. Алар тарафыннан күрсәтелгән гаять зур һәм сокландыргыч батырлыклар колхозчыларны тыныч хезмәт фронтында тагын да яхшырак эшләргә, үз постында намус белән эшләргә рухландыра.

— Без, үз постыбызда намус белән эшләвебез белән илебезнең экономик һәм оборона куәтен ныгытуга булышлык итәбез. Стахановча эшләү—ул батыр Кызыл Армиябезгә иң лаеклы бүләк. Фин халкының азатлыгы өчен, бөек социалистик Ватаныбызның тынычлыгы, бәйсезлеге өчен көрәштә Кызыл Армиябезнең җиңеп чыгуына нык ышанабыз. 23 нче февраль көненә, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе бәйрәменә данлы армиябез тагын да бер тарихи җиңү сәхифәсен язачак. Без бу көнгә бүләк итеп, язгы чәчүгә отлично хәзерләнүне, 1940 нчы елда тагын да югарырак уңыш алуны ышандырабыз, ди колхоз председателе иптәш Герасимов. Беседаны тыңлаучылар бу сүзләрне куәтләп, кул чабалар...

***

„Память Ленина“ колхозы членнары ике ел инде, Столбище районында алдынгылыкны тоталар. Бу колхоз нигездә яшелчәчелек колхозы. Колхозның уңышлары зур. 1939 нчы ел колхозга тагын да зуррак казанышлар китерде. Колхоз һәрбер гектардан уртача 55 центнер бәрәңге, 270 центнер кыяр, 110 центнер суган, 165 центнер чөгендер, 175 центнер помидор уңышы алуга ирешә. 1938 нче елда колхозның валовой продукция буенча доходы 88.335 сум, акчалата доходы 87 мең 509 сум тәшкил иткән булса, 1939 нчы елда доход валовой продукция буенча 162 мең 28 сумга, акчалата 177 мең 667 сумга җитте.

Югары уңыш өчен көрәштә стахановчы-ефремовчы звеноларның казанышлары аеруча зур. Мәсәлән, 3 нче бригаданың югары уңыш участкысыннан һәр гектарга 114 пот бодай уңышы алынды. Беренче бригадада иптәш Липатова звеносы гектардан 247 центнер кишер, 3 нче бригадада иптәш Защитникова звеносы 436 центнер, 2 нче бригадада иптәш Усачова звеносы 400 центнер кәбестә, 1 нче бригадада иптәш Белозеров звеносы гектарыннан 256 центнер кыяр уңышы алдылар. Мондый мисалләрне тагын да күп кенә китерергә мөмкин.

— Җиңүнең сере—агротехника чараларын дөрес итеп тормышка ашыруда, социалистик ярыш байрагын югары тотуда һәм звенолап эшләүдә,—ди колхоз председателе иптәш Герасимов.

Колхоз дәүләт алдындагы йөкләмәләрен вактыннан элек үтәде. Ферма терлекләрен һәм атларны туйдыру өчен тиешле азыклар кирәгеннән артык хәзерләнде. Чәчүлек өчен орлык җитәрлек һәм ул чистартылып та куелган. Колхоз дәүләткә планнан тыш 270 центнер яшелчә сатты.

Хәзер бу колхозда хезмәт көннәренә уңыш бүлү эше дә нигездә төгәлләнгән. Һәрбер хезмәт көненә 24,5 килограмм яшелчә һәм 2 сум акча туры килә. Мәсәлән, колхоз председателе иптәш Герасимов үзенең хезмәт көннәренә 22 тонна яшелчә һәм 1.800 сум акча, колхоз шоферы иптәш Кайнов 30 тонна яшелчә һәм 3 мең сум акча алды. Колхозның карт члены, 58 яшьлек иптәш Защитин үзенең хезмәт көннәренә 17 тонна яшелчә, 1.700 сум акча, звено башлыгы Настя һәм Нюра Чечкановалар семьясе 20 тонна яшелчә һәм 3.200 сум акча, рядовой колхозчы иптәш Ильин семьясе 20 тонна яшелчә, 3.000 сумнан артык акча алдылар һ. б.

Намуслы хезмәт колхозга әнә шундый казанышлар китерде. „Память Ленина“ колхозчыларын бу уңышлар гына тынычландырмый. Алар 1940 нчы елда тагын да мулрак уңыш алу өчен көрәшәләр. Бу теләккә ирешү өчен анда зур көрәш бара.

Колхозда ефремовчы 18 звено оештырылган. Бу звенолар үз участкыларында һәр гектардан 700 центнер кәбестә, 450 центнер кыяр, 700 центнер бәрәңге, 300 центнер суган, 500 центнер кишер уңышы алырга сүз бирәләр. Үз йөкләмәләрен үтәү өчен ефремовчы звено членнары тулысы белән агротехниканы өйрәнү түгәрәкләрендә укыйлар. 6 занятие үткәрелгән дә инде.

Колхоз басуларына 1.000 йөк тирес, 170 центнер минерал ашламалар чыгарылган. 30 центнер көл җыелган. 113 гектар җирдә кар тоту үткәрелгән. Авыл хуҗалыгы инвентарьларын ремонтлау эше якын көннәрдә тулысы белән төгәлләнә. Колхоз, 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашуга кандидат.

„Память Ленина“ колхозы әнә шулай үсә, шулай ныгый. Колхозчыларның культуралы тормышлары чәчәк ата.

Ким Биков.

БУЛАККА РЕКОНСТРУКЦИЯ

Казан шәһәрен төзекләндерүгә, урамнарга, мәйданнарга, тротуарларга таш һәм асфальт җәюгә, шәһәрне, аның окраиналарын яшелләндерүгә, яңа йортлар салуга һәм башка шундый төзеклек эшләренә дәүләт тарафыннан һәр ел саен гаять күп средстволар бирелә. 1939 нчы елны булакка башланган реконструкция ясау әнә шул төзеклек эшенең зур бер тармагы. Ул реконструкция зур Казан планы нигезендә үткәрелә.

Үткән ел булакта шактый зур эш башкарылды инде. Булакның төбен тирәнәйтү һәм ярларын тигезләү буенча 34.467 кубометр балчык чыгарылды. Һәр ике яр башын яшелләндерү зоналары билгеләнде. Реконструкциянең бу өлешенә 570 мең сум акча тотылды.

1940 нчы елны реконструкция дәвам итәчәк. Җир казу, 3 метр тирәнлегендә су асты ярларына таш түшәү, Булакның һәр ике яр башына асфальт юллар җәю, яшелләндерү, Триумфаль урамы янында плотина төзү эшләрен тәмам итү планлаштырыла. Быел төзелешкә дәүләт тарафыннан 2 миллион сум акча бирелә.

Булакка реконструкция ясау 1941 нче елны төгәлләнергә тиеш. Алдагы елда причаллар төзү, ярларга плитәләр җәю эшләре башкарылачак. Реконструкция тәмам булып, булак эксплоатациягә биреләчәк.

Ташландык хәлендә яткан булак хезмәт ияләренең иң яратып ял итү урны булып әвереләчәк. Кремльдән алып Кабан күленә кадәр су трамвайлары, катерлар йөреп торачак.

Уңышлы башланган эшне уңышлы төгәлләү өчен, югары сыйфатлы итеп реконструкция ясау өчен шәһәрнең җәмагат оешмалары зур ярдәм итә алалар. Үткән елны „Спартак“ комбинаты коллективы чакыруына Казанның байтак җәмагат оешмалары (4 нче номерлы ясалма каучук заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклар коллективы, „Труд“, „Вперед“ артелләре членнары) катнаштылар. Казан шәһәренең предприятиеләре, артелләре, учреждениеләре, төрле җәмагат оешмалары булакны реконструкцияләү эшенә быел да ярдәм итәргә тиешләр. Ә шәһәр советы җитәкчеләре реконструкцияне срогында төгәлләү өчен бөтен эшне җентекләп оештырырга, дәүләт тарафыннан бирелә торган гаять зур средстволарны урынлы тоту һәм алардан тулы файдалану өчен барлык шартларны тудырырга бурычлылар.

Сәлим.

БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР

(„Нәни китап“ сериясе чыгуга карата)

Балалар әдәбияты издательствосы—Детиздат ничә еллар инде рус телендә „Книжка малышка“ („Нәни китап“) сериясе чыгарып килә. Матур буяулы рәсемнәр белән бизәлеп, яхшы кәгаздә, миллион тираж белән басылган бу китаплар совет балалары өчен зур куаныч булып торалар.

Безнең Татгосиздат та шушы мактаулы эшкә тотынды. Ул шушы көннәрдә генә „Нәни китап“ сериясеннән татар телендә беренчә әсәр басып чыгарды. Бу беренче карлыгачлар безнең балалар әдәбияты шүрлеген тагын да матуррак бизәделәр һәм баета төштеләр.

Татгосиздатның яшьләр—балалар әдәбияты секторының 1939 нчы елгы планында мондый китапчыкларны 24 төрле исемдә бастырып чыгару күздә тотылган иде. Бу сектор белән җитәкчелек итүчеләрнең шушындый әһәмиятле эшкә салкын караулары аркасында, план бары 12 процентка гына үтәлде, 3 кенә китап чыгарылды.

Бу китапчыкларны кулга алу белән аларның беренче битләренә күз төшерәсен, аларның берсендә „Бәләкәйләр өчен“, икенчесендә „Нәниләр өчен“ дип язылган. Шушындый кечкенә атамада да берлек булмауга, башбаштаклыкка гаҗәпкә каласың. Өч китапның да редакторы бер лә баса! Редактор иптәш Ибраһим Газый нәрсә карады икән соң?

Китапчыкларның эчләренә кереп карыйк. Китапларның беренчесе—бер туган Гриммләрнең „Салам, күмер һәм ногыт борчагы“ исемле әсәрләре (Зәкия Садыйкова тәрҗемәсе). Ни өчендер аларның исемнәрен „Бр. Гримм“ дип кенә куйганнар. Ярыйла „Бр.“ дигәнне укучылар „братья“ дип укысалар! Икенчесе—Ж. Тәрҗемановның „Бал корты һәм ишәк“ әкияте, өченчесе—Хәй Вахитның „Уңган сыерчык белән шапшак чыпчык“ дигән әсәре.

Бертуган Гриммләрнең „Салам, күмер һәм ногыт борчагы“ исемле әсәрләре дөнья әдәбиятында танылган әсәр. Ул бердән балаларны бу өч әйбернең үзенчәлекләре белән таныштырса, икенчедән,—шул ук әйберләр аша аларга дусны, юлдашны белеп сайларга кирәклекне дә ачып бирә.

Ж. Тәрҗеманов иптәш үзенең „Бал корты һәм ишәк“ исемле әкиятендә тиз ышанучанлыкны һәм ахмаклыкны, җанлы суратләр һәм юморга тартым җиңел тел белән, бик оста рәвештә күз алдына китереп бастыра, Хәй Вахит иптәшнең „Уңган сыерчык белән шапшак чыпчык“ исемле әкияте уңганлык белән шапшаклыкны бик матур итеп суратли. Китаплар эчтәлекләре ягыннан файдалы һәм кирәкле китаплар.

Шушындый мактаулы эшкә керешкән Татгосиздат бу китапларның оформление ягына җитәрлек әһәмият бирмәгән. „Бал корты һәм ишәк“ китабында (художник Б. Әлминов эше) бал корты тараканга ошашлы, ә ишәкләр шулай ук бик килбәтсезләр. Монннан тыш китапта хәреф хаталары да күп кенә. Художник Ш. Мөхәммәтҗановның „Уңган сыерчык белән шапшак чыпчык“ка ясалган рәсемнәре оригиналында оста эшләнгән булсалар да, типографиядә шактый ук бозылганнар.

Татгосиздат работникларында „Нәни китап“ сериясенә гомумән начар караш яшәп килә.

Бу китапчыкларны басып чыгару өчен типографиядә барлык мөмкинлекләр булуга да карамастан, типография работниклары бу эшкә тиешле игтибарны бирмиләр. Издательство работниклары художникларның куллана торган буяу санын чиклиләр. Өч-дүрт төрле буяу белән матур рәсемнәр ясату урнына, алар рәсемнәрне ике буяудан гына эшләргә кушалар. Илебезнең бәхетле яш буыны өчен чыгарыла торган китапларның оформлениесе дә яхшы, югары сыйфатлы булырга тиеш.

Китапларның тиражы да бик аз куелган (10.000), шуңа күрә аларның бәяләре дә кыйммәт (25 тиен). Киләчәктә мондый китапларның тиражларын күбәйтә төшәргә кирәк.

„Нәни китап“ сериясе киләчәктә дә дәвамлы рәвештә чыгып барырга тиеш. Татгосиздат башлаган эшен ярты юлда туктатып калдырмасын, кирәкле эшкә керешкәч, аны уңышлы рәвештә дәвам иттерсен.

А. Алиш.

Шәриф Камал юбилее

Татар совет язучысы Шәриф Камалның әдәби һәм җәмагат эше башлавына шушы елның 25 нче февралендә 30 ел тула.

Юбилейгә хәзерлек һәм аны үткәрү буенча Татарстан Сәнгат Эшләре Комитеты начальнигы иптәш Назаров председательлегендә хөкүмәт комиссиясе төзелде. Комиссия махсус план төзеп эшкә кереште.

Юбилей уңае белән күп кенә чаралар үткәрү билгеләнә. Госиздат тарафыннан Шәриф Камалның рус телендә сайланма хикәяләре җыентыгы (7 басма табак күләмендә) чагарылачак. Җыентыкка язучының „Акчарлаклар“ дигән озын хикәясе һәм башка новеллалары кертелә.

Татгосиздат Ш. Камал әсәрләренең бертомлыгын чыгарырга хәзерләнә. Шулай ук „Матур туганда“ романының икенче басмасын чыгару һәм „Матур туганда“ пьесасын рус телендә басып чыгару күздә тотыла.

Татарстан Совет Язучылары Союзы, Тел һәм Әдәбият Институты белән берлектә, Шәриф Камал турында фәнни мәкаләләр хәзерли. Бу эш өстендә Кәшшаф Газый, Хәсән Хәйри, Фәйзуллина, Муса Җәлил, Халитов, Гайнуллин, Вазиева, Л. Җәләй, Х. Ярми һәм башка иптәшләр эшлиләр. Алар юбилей көннәрендә үзәк һәм җирле газеталарда һәм шулай ук, кардәш республикаларның матбугатында Шәриф Камал иҗады турында үзләренең мәкаләләре бирәчәкләр.

Юбилейне үткәрү комиссиясе тарафыннан Шәриф Камалның биографиясе эшләнә. Шулай ук докладчылар өчен тезислар хәзерләнә. Эшчеләр клубларында, колхозларда, Кызыл Армия частьләрендә докладлар, беседалар үткәрү, әдәби күргәзмәләр оештыру планлаштырыла.

25 нче февральдә, юбилей көнне, Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында юбилей кичәсе үткәреләчәк. Кичәдә „Шәриф Камалның тормышы һәм иҗады“ турындагы докладтан соң Татар Дәүләт Опера театры, Татар Дәүләт Академия театры һәм Татарстан Дәүләт Филармониясе артистлары көче белән зур концерт биреләчәк.

26 нчы февральдә Татар Дәүләт Академия театрында Шәриф Камал пьесаларыннан берсе куелачак.

СССР Совет Язучылары Союзы да Шәриф Камал юбилеен билгеләп үтәчәк. Юбилей көннәрендә СССР Совет язучылары Союзы президиумының Шәриф Камал иҗадына багышланган тантаналы җыелышы үткәрелә. Шәриф Камал катнашы белән Москваның язучылар йортында иҗад кичәсе булачак.

Р. Н.

Чкалов шәһәр хезмәт ияләре татар халкының классик язучысы Шәриф Камалның иҗади юбилеен үткәрүгә хәзерлек башладылар. Юбилейне үткәрү һәм аңа хәзерлек алып бару өчен Совет язучыларының Чкалов өлкә әдәбият группасы каршында юбилей комитеты төзелде. Бу комитетка шәһәрнең партия һәм совет оешмалары вәкилләреннән 8 кеше керде.

Юбилей комитеты расланган план буенча эш алып бара. Гыйнвар, февраль айларында Чкалов Өлкә газетасы битләрендә Шәриф Камалның иҗады һәм тормышы турында, шулай ук юбилейгә хәзерлек турында материаллар урнаштырылачак.

Яш язучы Абдрашитов Ш. Камалның „Матур туганда“ романыннан өземтәләргә тәрҗемә ясый. Бу тәрҗемә язучының портреты һәм биографиясе белән әдәби альманахта басылачак.

Шәһәрнең эре предприятиеләрендә Ш. Камалның иҗады һәм тормыш юлы турында 8 доклад үткәреләчәк. Шул тема буенча рус һәм татар телләрендә радио аркылы лекцияләр биреләчәк.

Юбилей комитеты председателе *Мирсәй Давыдов.*

Казан шәһәре яшьләре хәрби эшне өйрәнәләр. РӘСЕМДӘ: ПВХО инструкторы И. И. Христофоров Ленин исемендәге завод эшчеләренә аэро-бомба турында аңлата. Б. Мясников фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Допризывниклар җыелышында

Буа шәһәрендә допризывниклар җыелышы булды. Җыелышка җәмагат һәм ирекле оешмаларның вәкилләре катнашты. Көн тәртибенә чираттагы призывка хәзерлек мәсьәләсе куелды. Буа районы призывниклары 1940 нчы елгы призывка хәзерләнү буенча мөрәҗәгат кабул иттеләр. Анда түбәндәгеләр әйтелә:

Совет яшьләре Кызыл Армия сафларына китәргә, Кызыл Армиябезнең сафларын грамоталы һәм физик яктан таза сугышчылар белән тутырырга һәр вакыт хәзер торалар.

Кызыл Армиядә яшьләр үзләренең белем дәрәҗәләрен арттыруларын туктатмыйлар, киресенчә алар анда һәр яктан үсәләр, тагын да күбрәк көч җыялар һәм үзләренең белемнәрен тагын да ныграк күтәрәләр.

СССР Верховный Советының Гадәттән тыш IV нче Сессиясендә кабул ителгән гомуми хәрби хезмәт турындагы закон бөек социалистик илебез тормышында, совет халкы тормышында әһәмиятле вакыйга булды.

Гомуми хәрби хезмәт турындагы закон мәктәпкә гаять зур дәүләт функциясен—яшь гражданнарны үзләренең изге гражданлык бурычларын үтәүгә башлангыч хәзерлек эшен, кулга винтовка тотып, Ватанны сакларга хәзерләү эшен йөкли.

Без, Буа шәһәр допризывниклары призыв көненә тулы грамоталы булып киләчәкбез.

Сәламәт булмаган допризывниклар арасында системалы рәвештә дәвалау эшләре алып барып, без призыв көненә барыбыз да таза булып киләчәкбез.

Без, барлык предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, уку йортларында һәм колхозларда Ворошиловча атучы, ГСО, ПВХО түгәрәкләре оештырабыз һәм призыв көненә кимендә өчәр оборона значогы тагып килербез.

Без, гомуми хәрби хезмәт турындагы законны һәм халыкара хәлне тирәнтен өйрәнәчәкбез.

Без, үзебезнең гомуми һәм политик белемебезне күтәрү өстендә нык эшләп, чираттагы призывка кадәр үз арабыздан 20 снайпер һәм 30 шофер хәзерләячәкбез.

Без, Татарстан республикасының барлык допризывникларын чираттагы призывка 100 процент грамоталы булып, 100 процент физик яктан таза булып һәм кимендә өчәр оборона значоклары белән килергә чакырабыз.

Теләкләребезне тормышка ашыруда безгә партия, комсомол оешмаларының, барлык учреждениеләрнең, уку йортларының, барлык авыл советларының һәм ирекле җәмагат оешмаларының практик ярдәм итүләрен сорыйбыз.

КОЛХОЗЧЫЛАР ЗУР ДОХОД АЛАЛАР

Баулы районының „Ак урман“ колхозында колхозчыларның уңыш бүлүгә багышланган җыелышы үткәрелде. Колхоз председателе иптәш Әхмәтгәрәев колхозның 1939 нчы елда уртача түбәндәгечә уңыш алуы турында белдерде:

Тары уңышы гектардан 11,2 центнер, арыш—10,7 центнер, борчак—9 центнер, бодай—8,2 центнер һ. б.

Колхоз үзенең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен тулысы белән үтәде. Чәчүлек орлык, фураж һәм башка фондларны аерып куйды.

Колхозчы иптәш Сибгатуллин үзенең хезмәт көннәренә 362 пот ашлык, иптәш Ситдиков—252 пот, иптәш Хәләфиев—215 пот ашлык алдылар. Ашлыктан тыш һәр хезмәт көненә 6 шар килограмм терлек азыгы һәм 50 шәр тиен акча бүленде. Колхозчылар 1940 нчы елда һәр гектардан 120 пот уңыш алырга сүз бирделәр.

Авыл хуҗалыгы стахановчылары мәктәбе

Һәр гектардан йөз пот бөртекле иген уңышы алу өчен авыл хуҗалыгы кадрларының белемнәрен күтәрү теләге белән Норлат районының 12 колхозында стахановчылар мәктәпләре оештырылды. Хәзер бу мәктәпләрдә тәртипле рәвештә занятиеләр алып барыла.

ВКП(б) райкомы, колхозчылар арасында агитация-пропаганда эшләрен тагын да җәелдерү теләге белән, 23 колхозда авыл активы өчен политграмота түгәрәкләре оештырды. Агитация эшләре алып бару өчен райком тарафыннан 34 кеше беркетелде.

КОЛХОЗЛАР ӨЧЕН КАДРЛАР

Норлат районы үзәгендәге районара колхоз мәктәбендә умартачылык белгечләренә чыгарыш булды. Укуны тәмамлап чыгучыларның (барлык 19 кеше) 35 проценты хатын-кызлар. Шулардан 15 кеше укуны отлично һәм яхшы билгесенә тәмамлады. Комсомолец Мингәрәй Вафин һәм Гаязов иптәшләр имтиханнарны барлык фәннәр буенча да отлично билгесенә тапшырдылар. Алар һәм тагын 3 кеше мәктәп дирекциясе тарафыннан бүләкләнделәр.

А. Җәләл.

РАЙОН ҮЗӘГЕНДӘ КИНО

Кызыл Юл районы үзәгендәге клубта 1939 нчы елның декабреннән стационар кино эшли башлады. Колхозчылар һәм район хезмәткәрләре киноaccess бик яратып йөриләр. Шулай ук, кино карау өчен якын авыллардан да колхозчылар киләләр.

17 нче гыйнварда күрсәтелгән „Чиктә“ картинасын карау өчен күрше авыллардан 400 гә якын колхозчы килде.

А. Юнусов.

ЯҢА МУНЧА САЛЫНА

Кинопленка территориясендә торучы эшчеләр, хезмәткәрләр өчен яңа мунча салына башлады. Мунчада ванналы 8 кабина, душлы 16 кабина, ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым класслар булачак. Мунчаны төзү эшләренә 450 меңнән артык акча тотыла.

Хәзер җир һәм фундамент эшләре тәмам булды. Мунчаның стеналарын төзү эше башланды.

Р. Галиева.

БЕЛДЕРҮ

26 нчы гыйнварда, кич сәгать 7 дә Язучылар Союзында (Матбугат йорты, 5 катта) Р. Ишмурат һәм Фатхуллинның „Ялкынлы яшьлек“ (В. И. Ленинның студентлык елларын чагылдырган) пьесасы укыла. Язучы, тарихчы һәм башка иптәшләр чакырылалар.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Күңелсез фактлар һәм РОНО

Буденный районындагы күп кенә мәктәпләрдә укучы балаларның фәннәрне үзләштерүләре һич тә канәгатьләнерлек түгел. Уку елының беренче яртысы биргән күңелсез нәтиҗәләр бу турыда ачык сигнал була алалар. Мәсәлән, бөтен район буенча башлангыч мәктәпләрдә укучы барлык 2.015 баладан 201 бала, урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә укучы 4.587 укучыдан 988 е начар күрсәткечләр биргәннәр. Яңа Тинчәле, Иске Тинчәле авыллары мәктәпләре (директорлары Сагитов һәм Хафизов иптәшләр) бу мәсьәләдә аеруча артта баралар.

Өлгереш бигрәк тә рус теле буенча канәгатьләнерлек түгел. Кайбер укытучылар һәм район мәгариф бүлеге мөдире иптәш Әхтәмов: „татар балалары рус телен белмиләр“ дип үзләрен акларга маташалар. Мәсьәләгә мондый караш дөрес түгел һәм ул зарарлы. Укыту-тәрбия эшләре яхшы куелган мәктәпләрдә татар балалары рус телен беләләр һәм аны яхшы үзләштерәләр. Моны районның үзендә булган фактлар белән расларга мөмкин.

Менә Иске Шәйморза авылындагы урта мәктәп. Биредә югары классларда рус телен иптәш Ирзин укыта. Укучылар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелгән. Дәрестән артта калучыларга отлично укучылар ярдәм итәләр. Алар өчен өстәмә дәресләр оештырыла. Нәтиҗәдә, 112 укучыдан 8 генә кеше дәрестән өлгерми.

Орденлы укытучы иптәш Пигузов җитәкчелегендәге Иске Мөрәле мәктәбе уку елының беренче яртысын 100 процент өлгереш белән тәмам итте. Укытучылар коллективы ата-аналар арасында зур эш алып баралар. Мәктәптә оештырылган социалистик ярыш договорларының үтәлеше системалы рәвештә тикшерелә. Укыту-тәрбия эшләрен югары баскычка күтәрүдә тырышлык күрсәткән укытучылар әнә шундый гүзәл нәтиҗәләрне бирәләр.

РОНО ның мәктәпләргә җитәкчелеге җитәрлек түгел. РОНО работниклары мәктәпләрдә очраклы рәвештә генә булалар. Укытучыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу практик эштә бик аз кулланыла. Укытучыларның күпчелеге яшьләр булуын искә алып, тәҗрибәне уртаклашуны күбрәк кулланганда, һич шиксез, уңышлы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин булган булыр иде. Кайбер укытучыларның эшләренә тиешле контроль ясамау аркасында дәресне „сәгать үтсен“ дип кенә алып бару фактлары да юк түгел.

Кырык Садык авылы мәктәбенең 5 нче классларында тарих фәнен иптәш Чубаев укыта. Ул дәрескә хәзерләнми керә һәм шунлыктан, тиешле нәтиҗәне бирә алмый. Зур Чынлы авыл мәктәбенең 4 нче классында тарих укытучысы иптәш Гайнуллина да дәрескә бетенләй хәзерлексез керә. Мондый һәм моңа охшашлы фактларны районда еш кына очратырга мөмкин, ләкин РОНО работниклары алар белән кызыксынмыйлар.

Уку елының беренче яртысында булган күңелсез фактларга большевистик анализ биргәндә, РОНО работниклары һәм мәктәп директорлары үз эшләрендә текә борылыш ясауга һәм быелгы уку елын зур уңышлар белән төгәлләүгә ирешә алачаклар. Моның өчен районда бөтен мөмкинлекләр бар. Бары тик большевикларча эшләргә генә кирәк.

А. Яфизов.

„Вәли Галигә, Гали Вәлигә...“

Тимер юлның Кукмара станциясендә зурларны укыту эше оештырылмаган, чөнки станция җитәкчеләре бу эшкә әһәмият биреп житкермиләр, профсоюз оешмасы җитәкчесе иптәш Гафиятуллин: „Зурларны укыту РОНО һәм комсомол оешмасы эше“ ди. Ә РОНО ның зурларны укыту эше буенча инспекторы иптәш Газизов: „Безнең эш түгел, бу профсоюз оешмасы эше“ ди. Шулай итеп, алар зурларны укыту кебек әһәмиятле мәсьәләне өзүгә таба алып баралар.

Тимер юл станциясенең мәктәпләр секторы станциядә зурларны укыту буенча эшлекле чаралар күрер дип ышанабыз.

А. С.

ЯҢА ФАБРИКА-КУХНЯ ТӨЗЕЛӘ

Куйбышев исемендәге Кинопленка фабрикасы территориясендә гыйнвар аенда фабрика-кухня төзелә башлады. Аны төзү эшләренә 1 миллион сум акча җибәрелде.

Фабрика-кухня янында 240 урынлы ашханә, 40 урынлы кафе, 60 урынлы закусочный, 60 урынлы диэт-ашханә эшләячәк.

Клуб начар эшли

Норлат районы Кара Шәм авылы „Яңалиф“ колхозында массага культура хезмәте күрсәтү начар оештырылган. Клуб еш кына бикле була. Аның мөдире Шәфигуллина үз эшенә җавапсыз карый, хәтта аның эш планы да юк.

Клубта ирекле түгәрәкләр дә эшләми. Допризывниклар арасында бер төрле дә эш алып барылмый.

Бу клубның эше белән РОНО җитәкчеләре һич кызыксынмыйлар. Клуб бинасына ремонт үткәрелгәне юк.

Район советы башкарма комитеты һәм район мәгариф бүлеге культура-масса эшләрен яхшырту өчен конкрет чаралар күрергә тиешләр.

Г. Сиражиев.

ЛЕКЦИЯЛӘР ӨЛКӘ БЮРОСЫ

1940 нчы елда иҗтимагый-политик темаларга, халыкара хәлләр, оборона, дингә каршы, фәнни-табигать, әдәби, хәрби-тарихи, медицина, авыл хуҗалыгы темаларына һәм башка темаларга

ЛЕКЦИЯЛӘР УКУ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ

Договор төзү мәсьәләләре буенча түбәндәге адрес белән лекцияләр бюросына килергә: Казан, Кремль, Татнаркомпрос, 2 нче бүлмә. Телефон 19—16. 138—1

КАЗАН ШӘҺӘР ТРАМВАЙ ИДАРӘСЕ

кондукторлар, вагон йөртүчеләр һәм слесарьлар хәзерләү курсларына

УКУЧЫЛАР АЛА

Уку сроклары: кондукторлар хәзерләү курсларында—20 көн. Стипендия айга 75 сум. Вагон йөртүчеләр курсларында—ике ай ярым. Стипендия айга 90 сум. Слесарьлар хәзерләү курсларында—2 ай. Стипендия айга 90 сум.

Курсларга 18 яшь тулган һәм аннан югары яштәге кешеләр кимендә 4 класс күләмендәге белем белән алыналар. Ялгызларга, медицина тикшерүе комиссиясе үткәннән соң тулай торакта урын бирелә.

Гаризалар шушы ел, 1 нче февральгә кадәр алына. Документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Ершов кыры, 1, бүлмә № 6. 121—3—2

КИРӘК:

ЮВЕЛИРТОРГ МАГАЗИНЫНА ДАИМИ ЭШКӘ БУХГАЛТЕРЛАР. Бауман урамы, 58. Телефон 11—93. 126—1

Казан Авиация институтына даими эшкә БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, КАРТОТЕКАЧЫ, ЧЕРТЕЖЧЫ, чит илләрдә чыга торган журналларны ТӘРҖЕМӘ ИТҮЧЕ, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, КИЕМ ЭЛГЕЧЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, ОХРАННИКЛАР, МЕТАЛЛ ЮНУЧЫЛАР, ЖИТЕШТЕРҮ БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ УРЫНБАСАРЫ, кадрлар учеты буенча СТАТИСТИК һәм ҮТӘҮЧЕ, ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, 6—7 нче РАЗРЯД СЛЕСАРЬЛАР, 6—7 нче РАЗРЯД ТОКАРЬЛАР һәм сантехника буенча СЛЕСАРЬЛАР. Институтның кадрлар бүлегенә килергә. Казан, Миславский урамы, 10. 128—2—1

Бондюг заводына, баш энергетик хезмәтләрен үтәү өчен, ПРАКТИК ЭШ СТАЖЛЫ ИНЖЕНЕР - ЭНЕРГЕТИК. Гариза белән бергә белгеч үзенең белгечлеге буенча эш стажы турында белешмә бирергә тиеш. Татарстан АССР, Бондюг заводы, кадрлар бүлеге. 124—3—3

Киров Райпищеторгына даими эшкә БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОР, ДӘГВАЛАР БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕ БУХГАЛТЕР, БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЫ, МАГАЗИНДА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР һәм БУХГАЛТЕР-ИНСТРУКТОР. Хезмәт хакы килешү буенча. Ягодный бистәсе, Базар мәйданы. Телефон 9—63. 112—2—2

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн

Москва 4 нче труппасының гастрольләре

ИНТЕРМЕДИЯ

ЧИК ЙОЗАКТА

Кич 8 дә башлана.

АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы

ЗОЛЛО гастрольләре

Атнаның икенче көнендә цирк эшләми. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

1 нче февраль кич 5 сәгаттә, Казан, Дәүләт Ветеринария институтының паталогик анатомия кафедрасы аудиториясендә институт гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм ветеринария фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен түбәндәге темаларда халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ үткәрелә:

1. Казан Ветеринария институты доценты Н. Н. Солдатов. Тема: „Яткан вактында дуңгызның, иДәннең нинди материалдан булуына карап чагыштырма рәвештә иДәнгә төрлечә елылык бирүе“.

Рәсми оппонентлар: фәннәр кандидаты доцент Е. Н. Павловский һәм фәннәр кандидаты доцент А. М. Барсков.

2. Казан Дәүләт Ветеринария институты ассистенты З. С. Сафин. Тема: „Йорт куяннарына чина ашату“.

Рәсми оппонентлар: фәннәр кандидаты доцент А. М. Барсков һәм фәннәр кандидаты доцент Х. Ш. Казаков.

Диссертация материаллары белән институт көтепханәсендә танышырга мөмкин. 131—1

ГАЗ маркалы, 1,5 тонналы төзек хәлендәге

АВТОМАШИНАБЫЗНЫ газогенераторлы автомашинага алмашабыз

Казан, Лаврентьев урамы, 55. Росглавпиво. Телефоннар: 17—52 һәм 13—06. 54—2—2

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

Бүген, 26 нчы гыйнварда

КЫЮ КЫЗЛАР

Талон 104.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

26, 27 һәм 28 нче гыйнварда

МАСКАРАД

Талоннар: 26 нчы гыйнварда 84, 27 нче гыйнварда 85.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 1, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН һәМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ТАЙГА ЕРАКЛЫКЛАРЫНДА
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич УКЫТУЧЫ. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	Степан Разин

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2491 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 340.